АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2019 №224

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
муниципаль милкендә булган җир
кишәрлекләре өчен аренда түләвенең
күләмен билгеләү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү
турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы прокуратурасының 11 декабрь, 2018 ел, № 02-08-01-2018 санлы протестын үтәү йөзеннән, шулай ук гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, шул исәптән 2017 елның 13 сентябрендә үзгәртелгән “Җир өчен аренда түләве турында”гы 9 февраль, 1995 ел, 74 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль милкендә булган һәм Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 11 июль, 2017 ел, 106 нчы санлы Карары белән расланган сатулашмыйча гына арендага тапшырылган җир кишәрлекләре өчен аренда түләвенең күләмен билгеләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
муниципаль милкендә булган
һәм сатулашмыйча гына арендага тапшырылган
җир кишәрлекләре өчен аренда түләвенең

күләмен билгеләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
Кушымта

Җир кишәрлекләреннән файдалану төрләрен
исәпкә алучы
өстәмә коэффициентлар исемлеге

| Җир кишәрлегеннән файдалану төре | Коэффициент |
|---|---|
| Авыл хуҗалыгы производствосы өчен | 1,0 |
| Торак, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача төзү өчен | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектлары өчен | 1,0 |
| Электр станцияләре урнаштыру, аларга хезмәт күрсәтә торган корылмалар һәм объектлар өчен | 1,0 |
| Портлар, су вокзаллары, автоюл вокзаллары, аэровокзаллар кую өчен билгеләнгән объектлар өчен | 1,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару, тимер юллар, автомобиль юллары, ясалма эчке су юллары, причаллар, пристаньнәр, тимер һәм автомобиль юллары, су юллары өчен отвод полосалары, транспорт, энергетика һәм элемтәнең җир өстендәге һәм җир астындагы биналары, корылмалары, җайланмаларын куллану, тоту, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү өчен кирәк булган конструктив элементларның һәм корылмаларның, объектларның трубопроводлары, элемтә һәм радиофикациянең радиолиния һәм һава линияләре, электр үткәрүнең һава линияләре, спутник элемтәсе өчен җир өстендәге корылмалар һәм инфраструктурасын, космик эшчәнлек объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре | 1,0 |
| Склад объектлары өчен | 1,0 |
| Административ биналар һәм офислар өчен | 2,0 |
| Күпләп сату объектлары өчен | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектлары өчен | 4,0 |
| Ваклап сату (кибетләр, павильоннар, ваклап сату киосклары), базарлар, даруханәләр объектлары өчен | 10,0 |
| Кунакханәләр өчен | 5,0 |
| Банк, иминият, биржа эшчәнлеге өчен объектлар (шул исәптән түләү терминаллары) | 10,0 |

| | |
|---|---|
| Реклама (аслыкларда урнашкан реклама щитлары һәм стендлары) объектлары өчен | 75,0 |
| Гаражлар өчен | 1,0 |
| Ачык автомототранспорт кую урыннары өчен | 3,0 |
| **Автосерв**ис һәм и автозаправка станцияләре өчен объектлар | 4,5 |
| Ябык күп дәрәҗәле һәм җир асты автомототранспорты кую урыннары өчен | 1,0 |
| Төзелеш чорына ябык күп дәрәҗәле һәм җир асты автомототранспорты кую урыннары өчен | 1,0 |
| Махсус машина кую урыннары өчен (тоткарланган транспорт чараларын кую өчен) | 0,1 |
| Чистарту корылмалары өчен объектлар | 0,1 |
| “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүне дәүләт яклавы турында”гы 27.12.2004, 69-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган торак һәм объектлар өчен | 0,1 |
| Гражданнар авиациясе объектлары өчен | 0,1 |
| Спорт объектлары һәм корылмалары өчен | 0,17 |
| Рекреация һәм дәвалау-сәламәтләндерү объектлары өчен | 1,0 |
| Әйләнештәге су асты объектлары | 1,0 |
| Скверлар, парклар биләгән объектлар өчен | 1,0 |
| Башка объектлар өчен | 2,0 |
| Гражданнар, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәваланучыларны озатып йөрүче кешеләргә вакытлыча бушлай яшәү өчен билгеләнгән объектлар өчен | 0,1 |
| Медицина, социаль, психологик, юридик ярдәм ( шул исәптән төзелеш чорына) күрсәтү өчен билгеләнгән хәйрия фондлары биналары, корылмалары өчен | 0,01 |
| Су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар (су ресурсларын файдалану һәм саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу (буаларны, су агызу корылмаларын кертеп) өчен билгеләнгән су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар, суднолар йөри торган шлюзлар; судноларны күтәргечләр, су басулардан, сусаклагыч ярларын, елга юллары ярларын һәм төпләрен җимерелүдән саклаучы корылмалар , дамбалар, яр буйларын ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктуралары объектлары, пирслар, техник су белән тәэмин итү корылмалары, аларны булдыру, төзү, файдалану, | 0,1 |

| | |
|---|---|
| реконструкцияләү, модернизацияләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 3 нче пунктчасы һәм “Концессион килешүләр турында” гы 21 июль, 2005 ел, 115-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр нигезендә тормышка ашырыла. | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 3 нче пунктчасы нигезендә бирелгән һәм " Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 25нче пунктчасы яки “Концессион килешүләр турында”-гы 21 июль, 2005 ел, 115-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш булган җир кишәрлекләрендә булдырылган объектлар өчен | 0,1 |
| Су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар (су ресурсларын файдалану һәм саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу (буаларны, су агызу корылмаларын кертеп) өчен билгеләнгән су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар, суднолар йөри торган шлюзлар; судноларны күтәргечләр, су басулардан, сусаклагыч ярларын, елга юллары ярларын һәм төпләрен җимерелүдән саклаучы корылмалар җимерелүдән саклаучы корылмалар, дамбалар, яр буйларын саклау корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктуралары объектлары, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 25 нче пунктчасы нигезендә төзелгән аренда килешүе нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз акчаңа һәм (яки) бурычка алынган акчага булдырырылган техник су белән тәэмин итү корылмалары, | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 3 нче пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектлары өчен | 0,5 җир кишәрлеген арендалауга килешү төзелгән вакыттан алып 5 ел срокка |

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми порталында, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча Алексеевск муниципаль районы Советының даими депутатлар комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**